**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 ноябрендәге 4741 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2019 елның 23 сентябрендәге 3388 номерлы карары белән расланган**
**«33 Хәрби шәһәрчек» территориясен планлаштыру проектына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 августындагы 3677 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 23 сентябрендәге 3388 номерлы карары белән расланган «33 Хәрби шәһәрчек» территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр әзерләү турында»гы карарына таянып, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 23 сентябрендәге 3388 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 декабрендәге 3298 номерлы, 2022 елның 26 августындагы 2862 номерлы,

2023 елның 25 апрелендәге 1180 номерлы, 2024 елның 30 сентябрендәге 4125 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «33 Хәрби шәһәрчек» территориясен планлаштыру проектына, аның аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 23 сентябрендәге 3388 номерлы карары белән расланган «33 Хәрби шәһәрчек» территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 2 номерлы кушымтадан (хезмәт урынында файдалана торган материал) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 ноябрендәге
4741 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2019 елның 23 сентябрендәге 3388 номерлы карары белән расланган
«33 Хәрби шәһәрчек» территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләрне, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләрен, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрен күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә, кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә.

2. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турында, шулай ук территорияне план буенча үстерүнең характеристикалары турында нигезләмәдә:

2.1. 2 нче «Капиталь төзелеш объектларына характеристика» бүлегендә:

2.1.1. «Планлаштырыла торган социаль-көнкүреш һәм мәдәни билгеләнештәге төп объектлар» таблицасын түбәндәге эчтәлектәге юллар белән тулыландырырга:

| **Билгеләнеше** | **Атамасы** | **Җир кишәрлеге мәйданы (га)** |
|---|---|---|
| «И-13 | Блоклы-модульле котельный | |
| И-14 | Блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе-7 | Якынча урнашу урыны |
| И-15 | Блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе-8 | Якынча урнашу урыны» |

2.1.2. түбәндәге эчтәлектәге «2 номерлы участок территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү проектының төп техник-икътисади күрсәткечләре» таблицасын өстәргә:

**«2 номерлы участок территориясен планлаштыру проектына
үзгәрешләр кертү проектының төп техник-икътисади күрсәткечләре**

| №<br>т/б | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары төре | Мәйдан, га | Мәйдан өлеше, % |
|---|---|---|---|
| 1 | Күпкатлы торак йортлар урнаштыру зонасы (тугыз һәм аннан да күбрәк катлы) | 2,68 | 24,39 |
| 2 | Катлар саны уртача булган торак йортлар урнаштыру зонасы (мансарданы да кертеп, биштән алып сигез катка кадәр) | 0,86 | 8,18 |
| 3 | Режимлы объектларны урнаштыру зонасы | 6,52 | 61,47 |
| 4 | Белем бирү оешмаларын урнаштыру зонасы | 0,22 | 2,27 |
| 5 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрне урнаштыру зонасы | 0,151 | 1,52 |
| 6 | Махсус билгеләнештәге яшелләндерүне урнаштыру зонасы | 0,16 | 1,6 |
| 7 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы | 0,059 | 0,57 |
| Барлыгы | | 10,65 | 100» |

2.1.3. түбәндәге эчтәлектәге «Җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең иң чик параметрлары» таблицасы белән тулыландырырга:

**«Җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең иң чик параметрлары**

| Тер-рито-рияне план-лаш-тыру сызы-мында зона номе-ры | Зона төре | Зона мәйданы, га | Территория-дән рөхсәт ителгән файдалану коды | Капи-таль төзелеш объект-ларын-да катлар-ның макси-маль саны (кат) | Урнаштырыла торган объектларның тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Күпкатлы торак йортлар урнаштыру зонасы (тугыз һәм аннан да күбрәк катлы) | 2,68 | 2.6, 2.7, 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | Күпкатлы торак йортлар |
| 2 | Катлар саны уртача булган торак йортлар урнаштыру зонасы (мансардаларны да | 0,86 | 2.5, 2.7, 3.1.1 | 8 | Катлар саны уртача булган торак йортлар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кертеп, биш каттан сигез катка кадәр) | | | | |
| 3 | Белем бирү оешмаларын план буенча урнаштыру зонасы | 0,22 | 3.5.1, 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | 50 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, егәрлеге 6/0,4 кВ булган блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе-8 |
| 4 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын план буенча урнаштыру зонасы | 0,05 | 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | Егәрлеге 10,5 МВт (9,0 Гкал/сәг) булган блоклы-модульле котельный |
| 5 | Махсус билгеләнештәге яшелләндерүне план буенча урнаштыру зонасы | 0,16 | 12.0.2, 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | Егәрлеге 6/0,4 кВ (160 кВ/А) булган блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе-7 |
| 6 | Режимлы объектларны урнаштыру зонасы | 6,52 | 11.2. 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | |
| 7 | Инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыру зонасы | 0,009 | 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | 2827 номерлы блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе |
| 8 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрне план буенча урнаштыру зонасы | 0,078 | 12.0.2, 3.1.1 | Билге-лән-мәгән | |
| 9 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрне план буенча урнаштыру зонасы | 0,073 | 12.0.2, 3.1.1 | Билге-лән-мәгән» | |

2.2. 5 нче «Инженерлык-техник яктан тәэмин итү системасын үстерү характеристикасы» бүлегендә:

2.2.1. 5.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмасында хуҗалык ихтыяҗлары һәм эчү өчен файдаланыла торган суның тәүлеклек чыгымы 7,14 куб.м тәшкил итә, шул исәптән җәйге чорда территориягә су сибү өчен тотыла торган суның тәүлеклек чыгымы – 2,64 куб.м.

Техник мөмкинлекләр нигезендә планлаштыру проекты территориясен су белән тәэмин итүне Хәрби шәһәрчек-33 территориясендә булган Ø600 мм суүткәргечтән гамәлгә ашыру каралган.

Су белән тәэмин итү системасы хуҗалык һәм янгын сүндерү өчен кирәк булган ихтыяҗларны берләштереп кабул итеlә.

Проектта су белән тәэмин итүнең Ø63 мм, Ø110 мм челтәрләрен сузу каралган»;

2.2.2. 5.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Карап тикшерелә торган территориядә агынты суларның тәүлеклек чыгымы 4,50 куб.м тәшкил итә.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең техник мөмкинлекләре нигезендә мәктәпкәчә белем бирү оешмасыннан көнкүреш агынты суларын чыгарыла торган Ø225 мм канализация коллекторына агызу каралган. Ул мәктәпкәчә белем бирү оешмасын төзү зонасына эләгә.

Планлаштыру проекты белән түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру күздә тотыла:

- мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясеннән Ø150-225 мм канализация челтәрләрен чыгару;

- үзагышлы Ø110 мм челтәрләр төзү»;

2.2.3. 5.3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Проект белән әлеге территориядән яңгыр һәм кар суларын гамәлдәге нигезләмә буенча Ферма Шоссесы урамы районында «Алтын Яр» торак комплексы янындагы шәһәр урамы» линия объектының проект юлы ягына чыгарырга тәкъдим ителә»;

2.2.4. 5.4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Үзәк хәрби округ буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Үзәк торак-коммуналь идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалының 204 номерлы котельныйны, тузу сәбәпле, кулланыштан чыгару кирәклеге турындагы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә кулланучыларны 204 номерлы котельныйдан планлаштырыла торган, егәрлеге 10,5 МВт (9,0 Гкал/сәг) булган блоклы-модульле котельныйга күчерү турында карар кабул ителде.

Планлаштырыла торган, егәрлеге 10,5 МВт (9,0 Гкал/сәг) булган блоклы-модульле котельныйга түбәндәге кулланучыларны күчерергә тәкъдим ителә: 14 номерлы торак-коммуналь секторның 204 номерлы котельныена тоташтырылган торак-коммуналь сектор, 14 номерлы торак-коммуналь секторның 204 номерлы котельныена тоташтырылган Россия Федерациясе Оборона министрлыгы объектлары; Ярдәм урамы, 3 йорт адресы буенча

урнашкан күпфатирлы йорт. Шулай ук яңа кулланучылар сыйфатында түбәндәгеләрне тоташтырырга тәкъдим ителә: «Ак таш-Инвестстрой» махсуслаштырылган төзүче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан алып барыла торга төзелеш районында 220 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, Урта Кабан күле ермагы тирәсендә 50 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы.

Планлаштыру проекты белән түбәндәгеләр каралган:

- егәрлеге 10,5 МВт (9,0 Гкал/сәг) булган блоклы-модульле котельный төзү;

- проектлана торган блоклы-модульле котельныйдан җылылык челтәре салу;

- блоклы-модульле котельныйдан 6, 8 номерлы күпфатирлы йортларга тармакланып киткән урынга кадәр 360 м озынлыкта 2Ø325 мм җылылык үткәргеч төзү;

- 6, 8 номерлы күпфатирлы йортларга тармакланып киткән урыннан 4 номерлы күпфатирлы йорт янындагы 2Ø219 мм гамәлдәге җылылык үткәргечкә тоташтыру урынына кадәр 120 м озынлыкта 2Ø273 мм җылылык үткәргеч төзү;

- 12 номерлы күпфатирлы йортны һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасын 2Ø325 мм яңа җылылык үткәргечкә тоташтыру өчен 22 м озынлыкта 2Ø133 мм җылылык үткәргеч төзү;

- 6, 8 номерлы күпфатирлы йортларны 2Ø325 мм яңа җылылык үткәргечкә тоташтыру өчен 40 м озынлыкта 2Ø159 мм җылылык үткәргеч төзү;

- 4 номерлы күпфатирлы йорттан 1 номерлы күпфатирлы йорт янындагы җылылык камерасына кадәр гамәлдәге 2Ø219 мм җылылык челтәрләрен 2Ø273 мм җылылык челтәрләренә алмаштыру (370 м);

- җылылык камерасында Ярдәм урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортның (котельные түбәдә урнашкан) реконструкцияләнә торган 2Ø273 мм җылылык челтәрләренә тоташтыру өчен 50 м озынлыкта 2Ø219 мм җылылык үткәргеч төзү;

- Россия Федерациясе Оборона министрлыгы объектларын блоклы-модульле котельныйга тоташтыру өчен 14 номерлы күпфатирлы йорт янындагы яңа 2Ø325 мм җылылык үткәргечтән 204 номерлы котельный янындагы баш җылылык камерасына кадәр 110 м озынлыкта 2Ø125 мм җылылык челтәрләре төзү»;

2.2.5. 5.5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Яңа төзелеш объектлары тарафыннан электр куллану 181,5 кВт тәшкил

итә.

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең техник мөмкинлекләре нигезендә «Искож» подстанциясе (110 кВ) проектлана торган территория өчен туклану үзәге булып тора.

Планлаштыру проекты белән түбәндәгеләр каралган:

- котельныйны электр белән тәэмин итү өчен 6/0,4 кВ (160 кВ/А) блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе төзү;

- «Искож» подстанциясеннән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бинасына кадәр 6 кВ көчәнешле кабель линиясе төзү – 145 м;

- котельныйны электр белән тәэмин итү өчен блоклы комплектлы трансформатор подстанциясеннән 6 кВ көчәнешле кабель линиясе төзү – 96,4 м;

- 0,4 кВ көчәнешле 1н кертү-бүлеп тарату җайланмасы объектларында электр агымы көче 400А дан артмаган 0,4 кВ көчәнешле кертү-бүлеп тарату җайланмасы урнаштыру;

- 0,4 кВ көчәнешле кертү-бүлеп тарату җайланмасында өч фазалы ток кабул итү җайланмалары өчен саклану рәвешендә сүндерү җайланмасы урнаштыру, аларны җиргә тоташтыру, тулы булмаган фазалы режимда эшләүдән саклау (бер фазалы ток кабул итү җайланмаларын артык көчәнештән саклау) күздә тотыла;

- мәктәпкәчә белем бирү оешмасын электр белән тәэмин итү өчен аның территориясендә урнашкан, егәрлеге 6/0,4 кВ булган блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе төзү»;

2.2.6. 5.6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Планлаштырыла торган котельныйны газ белән тәэмин итү өчен 1255 куб.м/сәг газ кирәк.

«Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте мәгълүматларына караганда, 204 номерлы котельныйны газ бүлеп тарату челтәреннән өзгән һәм уртача басымлы 159 мм, 160 мм диаметрлы газүткәргеч участогын сүткән очракта, планлаштырыла торган котельныйны, уртача басымлы 426 мм диаметрлы газүткәргечкә тоташтырып, табигый газ белән тәэмин итү өчен техник мөмкинлек барлыкка килә.


Газны «Богородское» газ бүлеп тарату станциясеннән бирү күздә тотыла.

Планлаштырыла торган котельныйны газ белән тәэмин итү уртача басымлы Ø160 мм җир асты газүткәргече ярдәмендә гамәлгә ашыру күздә тотыла».

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 23 сентябрендәге 3388 номерлы карары белән расланган «33 Хәрби шәһәрчек» территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта




Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- граница фрагмента внесения изменений в проект планировки территории
- граница элемента планировочной структуры
- граница земельного участка
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- 3 — условные номера характерных точек устанавливаемых красных линий
- 1 — порядковый номер зоны размещения
- 1 — вид зоны размещения объектов капитального строительсва
- 1.9 — площадь зоны размещения (га)
- 3.5.1 — код вида разрешенного использования
- 10.1 — максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м/га)
- 9 — максимальная этажность (этаж)
- 1 — зона размещения многоэтажной жилой застройки (девять и более этажей)
- 2 — зона размещения среднеэтажной жилой застройки (от пяти до восьми этажей, включая мансардный)
- 6 — зона планируемого размещения образовательных организаций
- 11 — зона размещения объектов инженерной инфраструктуры
- 11 — зона планируемого размещения объектов инженерной инфраструктуры
- 18 — зона размещения режимных объектов
- 20 — зона планируемого размещения зеленых насаждений общего пользования
- зона планируемого размещения озеленения специального назначения
- сервитуты для подъезда к образовательным организациям

ЭКСПЛИКАЦИЯ

| Обознач. | Наименование | Площадь зем. участка, га | Примечание |
|---|---|---|---|
| Д-4 | Дошкольная образовательная организация на 50 мест | 0,22 | |
| И-13 | Блочно-модульная котельная | 0,05 | |
| И-14 | Блочная комплектная трансформаторная подстанция (БКТП-7) | - | БКТП-7 располагается в зоне озеленения специального назначения |
| И-15 | Блочная комплектная трансформаторная подстанция (БКТП-8) | | БКТП-8 располагается на территории дошкольной образовательной организации |

**Примечание:**

Перечень координат характерных точек устанавливаемых красных линий приведена в Приложении 1 к данному чертежу